**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы., Үзәк ур., 19

Тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**13 ноябрь 2023 ел** **№ 86**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 13.12.2019 №157 карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын тәртипкэ китерү максатларында (Советның 06.08.2020 № 225, 19.01.2021 № 24, 19.08.2022 № 60 карары редакциясендә), федераль һәм төбәк законнарына ярашлы рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьяларына таянып, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 статьялары, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы Карары проектын нигез итеп алырга һәм аны халык тыңлауларына чыгарырга.

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге «муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл

җирлеге Советы карары проекты буенча килгән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча оештыру комитетын (алга таба – оештыру комитеты) түбәндәге составта төзергә:
1) Гарифуллина З.Р. - Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы, оештыру комитеты рәисе;
2) Сабирҗанов Э.Р. - Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы депутаты - оештыру комитеты рәисе урынбасары;
3) Анастасов Г.Н. - Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы депутаты, оештыру комитеты әгъзасы.

4. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы карары проекты буенча Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урамы, 19 йорт адресы буенча 2023 елның 08 декабренә 13.00 сәгатьтә ачык тыңлаулар билгеләргә.

5. Җәмәгать тыңлауларын үткәрү буенча Оештыру комитетына «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне, исәпкә алуны, халык тыңлауларын үткәрүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Биектау районы Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урамы, 19 йорт адресы буенча урнашкан авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында куелган махсус мәгълүмат стендына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина

1 нче кушымта
Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 13.11.2023 № 86 карарына


**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9 51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**____________2023ел**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 13.12.2019 №207 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына (Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 06.08.2020 № 225, 19.01.2021 № 24, 19.08.2022 № 60 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. “Авыл торак пункты старостасы" 20 статьясының 2, 3 өлешләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл торак пункты старостасы авыл җирлеге гражданнары җыены тәкъдиме буенча, составына әлеге авыл торак пункты кергән авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә. Авыл торак пункты старостасы әлеге авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары, яки гражданнар җыены тәкъдим иткән көнне 18 яшен тутырган һәм

әлеге авыл җирлеге территориясендә урнашкан торак бинасы булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.

3. Авыл торак пункты старостасы дәүләт вазыйфасын, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны алмаштыручы зат түгел, үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан яки муниципаль хезмәт вазыйфасыннан тыш, хезмәт мөнәсәбәтләрендә һәм җирле үзидарә органнары белән турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрдә тора алмый.»

1.2. 32 статьяның 10 өлешендә "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

1.3. 32 статья “Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирлек башлыгы статусы” дигән 32 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 15 өлеш белән тулыландырырга:

«15. Депутат, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче бүтән зат Россия Федерациясендә һәм башка федераль законнарда коррупциягә каршы тору максатларында, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне, бурычларны үтәмәү күрсәтелгән затлардан бәйсез булган шартларда тикшерү тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында" Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә танылган очракта, «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә”.

1.4. “Җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату” 42 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 1.1 өлеше белән тулыландырырга:

«1.1. Җирлек Советы депутатының вәкаләтләре җирлек Советы карары белән, депутат җитди сәбәпләрсез алты ай рәттән җирлек Советының барлык утырышларында катнашмаган очракта вакытыннан алда туктатыла.»

1.5. 42 статьяның 5 өлешендә "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

1.6. 44 статьясындагы 1 өлешнең 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

1.7. “Җирлек башлыгы статусы” 45 статьясян түбәндәге эчтәлектәге 6 өлеш белән тулыландырырга:

«6. Җирлек башлыгы Россия Федерациясендә һәм башка федераль законнарда коррупциягә каршы тору максатларында, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм

таләпләрне, бурычларны үтәмәү аннан бәйсез булган шартларда тикшерү тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында" Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә танылган очракта, «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.

1.8. 48 статьядагы 3 өлешнең 2 абзацында «Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе» сүзләрен алыштырырга.

1.9. 48 статьяның 4 өлешендә "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

1.10. “Муниципаль норматив хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка чыгару) һәм үз көченә керү тәртибе” исемле 81 статьяның 8 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бастырып чыгарганда (халыкка чыгарганда) муниципаль хокукый актның реквизитлары күрсәтелергә тиеш.

Муниципаль хокукый актларны һәм җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрне рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юллары:

- муниципаль хокукый акт текстын яки муниципаль хокукый акт проектын "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ -веб-адресы буенча урнаштыру;

- муниципаль хокукый акт текстын авыл җирлеге территориясендәге авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштыру. Әлеге стендларның саны һәм урнаштыру урыннары җирлек Советы тарафыннан раслана һәм җирлек халкының муниципаль хокукый акт тексты белән тоткарлыксыз танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш;

- хокукый акт текстын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәве узганнан соң, Биектау районы Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урам, 19 йорт адресы буенча урнашкан авыл җирлеге башкарма комитеты банасында куелган махсус мәгълүмат стендына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясының 8 өлешенә ярашлы рәвештә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина

2нче кушымта
Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 13.11.2023 86 нчы санлы карарына

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу һәм гражданнарның фикер алышуда катнашу Тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проектны тикшерүдә гражданнарның тәкъдимнәрен һәм катнашуларын исәпкә алуның әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 4 пункты нигезендә, проектны тикшерүдә катнашу хокукын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында гражданнарның тәкъдимнәрен кертү тәртибен раслый.

2. Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге халкы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проект игълан ителгәннән бирле аны тикшерүдә түбәндәге формаларда катнашырга хокуклы:

1) яшәү урыны буенча гражданнар җыеннарын үткәрү;
2) Устав проектын әлеге тәртипкә ярашлы рәвештә массакүләм тикшерү;
3) Устав проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү;
4) гамәлдәге законнарга каршы килмәгән башка формаларда.

3. Тәкъдимнәр Алан-Бәксәр авыл җирлегенә түбәндәге адрес буенча бирелә: 422723, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урам, 19 йорт, телефоны 8(843)65-63-951.

3. Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәргә юридик затлар, иҗтимагый оешмалар, берләшмәләр өчен җитәкченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, яшәү урыны (гражданнар өчен), юридик адресы, имзасы һәм имзасының расшифровкасы күрсәтелергә тиеш.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында бастырылган проект буенча өстәмәләр һәм (яки) үзгәрешләр турында тәкъдимнәр (алга таба – халык тарафыннан ачык тыңлауларда тәкъдим ителгән тәкъдимнәр) ачык тыңлауларның йомгаклау документында күрсәтелә, ул Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу буенча Оештыру комитетына бирелә (алга таба эшче төркем).

5. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында бастырылган (игълан ителгән)

проектка халыкның тәкъдимнәре ул басылып чыккан көннән алып 20 көн эчендә эшче төркемгә кертелергә мөмкин һәм әлеге тәртипкә ярашлы рәвештә карала.

6. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү проекты буенча тәкъдимнәр Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә яшәүче, актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан кертелергә мөмкин.

7. Граждан (гражданнар төркеме) Устав проекты буенча тәкъдимнәрне кушымта буенча, әлеге Тәртипкә туры китереп рәсмиләштерә һәм аларны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу буенча эшче төркемгә җибәрә.

8. Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы депутатлары Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы Регламентында каралган тәртиптә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча тәкъдимнәр кертәләр.

9. Кертелгән тәкъдимнәр эшче төркем тарафыннан теркәлә.

10. Тәкъдимнәр Россия Федерациясе Конституциясенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына туры килергә тиеш.

11. Тәкъдимнәр түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

1) Устав проекты нигезләмәләрен берсүзсез аңлатуны тәэмин итәргә тиеш;

2) устав проектының башка нигезләмәләре белән каршылыкка яки килешмәүгә юл куймаска.

12. Әлеге тәртиптә каралган таләпләрне һәм срокларны бозып кертелгән тәкъдимнәр каралмыйча калдырылырга мөмкин.

13. Кертелгән тәкъдимнәрне өйрәнү, анализлау һәм гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча эшче төркем нәтиҗә ясый.

14. Эшче төркемнең кертелгән тәкъдимнәргә нәтиҗәсе түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш:

1) килгән тәкъдимнәрнең гомуми саны;

2) әлеге Тәртип буенча каралмаган тәкъдимнәр саны;

3) әлеге Тәртиптә куелган таләпләргә туры килмәү сәбәпле кире кагылган тәкъдимнәр;

4) эшче төркем тарафыннан кире кагылган тәкъдимнәр;

5) Устав проектының текстына кертү өчен эшче төркем тарафыннан тәкъдим ителгән тәкъдимнәр.

15. Эшче төркем Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге советына килгән барлык тәкъдимнәрне кушып, үз нәтиҗәсен һәм эшче төркем эшчәнлеге материалларын тәкъдим итә.

16. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проектны кабул итү (текстка кертү) яки тәкъдимнәрне кире кагу турындагы мәсьәләне хәл иткәнче, Биектау муниципаль

районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге советы эшче төркем җитәкчесе яисә эшче төркемнең вәкаләтле әгъзасының эшче төркем эшчәнлеге турындагы докладын тыңлый.

17. Кабул ителгән тәкъдимнәрне эчтәлеге буенча мәҗбүри үз эченә алган Устав проекты, гражданнардан килгән тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре халыкка игълан ителергә тиеш.

КушымтаТатарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Алан-Бәксәр авыл җирлеге
Уставына үзгәрешләр кертү турында
фикер алышуда гражданнарның
тәкъдимнәрен һәм катнашуларын
исәпкә алу тәртибенә

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына гражданнар тарафыннан кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча тәкъдим**

| № | Пункт, пунктча, статья | Устав проектының тексты | Төзәтмәнең тексты | Устав проектының тексты (төзәтмәләрне исәпкә алып) | төзәтмә кертүче |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча тәкъдимнәр керткән граждан (гражданнар төркеме) турында Мәгълүмат**

| | |
|---|---|
| Тәкъдимнәр керткән гражданных Фамилиясе, Исеме, Әтисенең исеме (булган очракта) | |
| Тору адресы, телефон | |
| Шәһси мәгълүматларны раслаучы документ | |
| Эш яки ук урыны | |

Гражданның (гражданнарның) имзасы Датасы